**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2026 елның 7 маендагы 1578 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2013 елның 26 августындагы 7669 номерлы**
**«Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**Юл хәрәкәте иминлеге комиссиясе турында»гы**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Составы Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 26 августындагы 7669 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының Юл хәрәкәте иминлеге комиссиясе турында»гы карары нигезендә расланган Казан шәһәре Башкарма комитетының Юл хәрәкәте иминлеге комиссиясенең кайбер әгъзалары китү белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 26 августындагы 7669 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының Юл хәрәкәте иминлеге комиссиясе турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 12 февралендәге 783 номерлы, 2015 елның 18 декабрендәге 4440 номерлы, 2017 елның 27 сентябрендәге 3798 номерлы, 2018 елның 19 июлендәге 4094 номерлы, 2020 елның 16 ноябрендәге 3316 номерлы, 2021 елның 18 ноябрендәге 3032 номерлы, 2022 елның 8 апрелендәге 989 номерлы, 2023 елның 20 февралендәге 547 номерлы, 2023 елның 22 августындагы 2364 номерлы, 2026 елның 6 июнендәге 2339 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 номерлы кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. әлеге карарга кушымтаны Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 26 августындагы 7669 номерлы карарына 2 номерлы кушымта дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 7 маендагы
1578 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**Юл хәрәкәте иминлеге комиссиясе**
**составы**

| | |
|---|---|
| Гафаров Рөстәм Гыйльфан улы | комиссия рәисе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе |
| Шакиров Илдар Сәетҗан улы | комиссия рәисе урынбасары, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары |
| Куляжев Игорь Владимирович | комиссия рәисе урынбасары, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары |
| Габитов Ринат Дамир улы | комиссия рәисе урынбасары, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Сидоров Алексей Васильевич | комиссия сәркатибе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитеты рәисе |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Савин Михаил Александрович | Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Большаков Андрей Иванович | Транспорт өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча дәүләт автомобиль юлы күзәтчелеге идарәсенең автомобиль һәм автомобиль юлы күзәтчелеге, халыкара пассажирлар йөртүне контрольдә тоту буенча төп бүлеге башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Чанкин Сергей Хәйдәр улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Гражданнарны яклау идарәсе башлыгы |
| Ризванов Ирек Асаф улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы |
| Шәмсетдинов Ренат Харрас улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе башлыгы |
| Салихов Альберт Иршат улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе башлыгы |
| Жаворонков Владимир Владимирович | Казан шәһәре Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе башлыгы |
| Фәтхетдинов Роман Рәмиз улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Совет районы администрациясе башлыгы |
| Яковлев Виктор Иосифович | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе урынбасары – хокук идарәсе башлыгы |
| Сәлимҗанов Илшат Илсур улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә идарәсе башлыгы |
| Абделхаков Әмир Айдар улы | Казан шәһәренең «Юл хәрәкәте белән идарә итүнең автоматлаштырылган системасы» муниципаль казна учреждениесе директоры |
| Агишев Наил Сәгыйдулла улы | Казан шәһәрендә «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенең территориаль идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Горбунов Алексей Павлович | «Шәһәрне үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе директоры |
| Ханморзин Зөлфәт Зарифулла улы | «Главтатдортранс» дәүләт казна учреждениесе директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Тедеев Сармат Аланович | Татарстан транспорт прокуроры урынбасары (килешү буенча) |